ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.12.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2580**

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гаиләдә белем алу һәм үзлектән белем алу формаларында гомуми белем алу турында нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе гражданнарының гомуми белем алу формасын сайлауга хокукларын тәэмин итү максатларында, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 17, 34, 58, 63 статьялары, «Гаилә формасында белем алуны оештыру турында» 2013 елның 15 ноябрендәге НТ-1139/08 номерлы РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының хаты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гаиләдә белем алу һәм үзлектән белем алу формаларында гомуми белем алу турында нигезләмәне расларга.
2. 2 нче кушымта нигезендә баланың гаиләдә белем алу формасында гомуми белем алу турында хәбәрнамә формасын расларга.
3. 3 нче кушымта нигезендә үзлектән белем алу формасында гомуми белем алу турында хәбәрнамә формасын расларга.
4. 4 нче кушымта нигезендә гомуми белем бирү оешмасында арадаш аттестация узу турында белешмә формасын расларга.
5. 5 нче кушымта нигезендә гаиләдә белем алу яисә үзлектән белем алу формасында белем алучы балаларны исәпкә алу кенәгәсе формасын расларга.
6. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – мәгариф идарәсе башлыгы Р.В.Афанасьевага йөкләргә .

Җитәкче И.Р. Ганиев

1нче кушымта
ТР ЗМР Башкарма комитеты
карарына
26.12.2020 ел №2580

**Зеленодольск муниципаль районында гаиләдә белем алу һәм үзлектән белем алу формасында гомуми белем алу турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гаиләдә белем алу һәм үзлектән белем алу формасында гомуми белем алу тәртибен билгели.

Гаиләдә белем алу- дәүләт аккредитациясе булган, тиешле белем бирү программасы буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы учреждениедә арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстрен рәвештә үтү хокукында, укучыларга башлангыч гомуми, төп гомуми белем бирү программаларын гаиләдә үзләштерүне күздә тоткан белем алу формасы.

Үзлектән белем алу - дәүләт аккредитациясе булган, тиешле белем бирү программасы буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы учреждениедә арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстрен рәвештә үтү хокукында, укучыларга урта гомуми белем бирү программасын мөстәкыйль үзләштерүне күздә тоткан белем алу формасы.

1.2. Балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) һәм төп гомуми белем алган яки унсигез яшькә җиткән укучылар, белем алу формасын сайларга хокуклы.

1.3. Балигъ булмаган укучының ата-аналары (законлы вәкилләре) гомуми белем алу формасы сайлаганда, баланың фикере исәпкә алына.

1.4. Башлангыч гомуми, төп гомуми белем бирү программаларын гаиләдә белем алу формасында һәм урта гомуми белем бирү программасын үзлектән белем алу формасында белем алу федераль дәүләт белем бирү стандарты белән билгеләнә.

1.5. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче, гаиләдә белем алу һәм үзлектән белем алу формаларында белем алучы укучыларның исәбен, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе гамәлгә ашыра.

## II. Гаиләдә белем алу һәм үзлектән белем алу формаларында гомуми белем алу тәртибе

2.1. Балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) һәм төп гомуми белем алган яки унсигез яшькә җиткән укучылар, гомуми белем алуның теләсә кайсы баскычында һәм укуның теләсә кайсы этабында гаиләдә белем алу, үзлектән белем алу формасын сайлап алырга хокуклы.

2.2. Төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яше тулганнан соң, ата-аналары (законлы вәкилләре) балалары гаиләдә белем алу формасында гомуми белем алу рәвешен сайлаганда, ата-аналар (законлы вәкилләр), укучылар язмача бу хакта Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә хәбәр итәләр.

2.3. Белем бирүнең әлеге формасын сайлаган ата-аналар (законлы вәкилләр) мәгариф оешмаларында белем алудан баш тарта һәм гаиләдә белем алу формасында килеп туган йөкләмәләрне үз өстенә ала.

2.4. Белем бирү эшчәнлеген гаиләдә белем алу яки үзлектән белем алуны гамәлгә ашыручы оешмалардан тыш, гомуми белем бирү программаларын үзләштергән очракта, югарыда аталган категория укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) мәгариф оешмасына элек укыган белем бирү оешмасының контингентыннан төшереп калдыру турында гариза белән мөрәҗәгать итәләр.

2.5. Балигъ булмаган бала элек укыган мәгариф оешмасы контингентыннан чыгарылганнан соң, балигъ булмаган укучының ата-анасы (законлы вәкилләре) белем алуның гаиләдә белем алу формасына күчү яки үзлектән белем алуы сәбәпле, җиде эш көне дәвамында түбәндәгеләргә бурычлы:

- укучы арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн сыйфатында узачак дәүләт аккредитациясе булган, тиешле белем бирү программасы буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмасын сайларга;

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә мәгариф оешмасын сайлап алу турында хәбәр итәргә һәм укучы арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн сыйфатында узачак мәгариф оешмасы боерыгын тапшырырга.

2.6. Мәгариф оешмасы һәм балигъ булмаган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре), укучылар арасында гаиләдә белем алу яки үзлектән белем алу формасын сайлаганда, аларга төп гомуми белем алганнан соң яисә унсигез яшь тулганнан соң, белем бирү оешмасы җитәкчесе боерыгы белән аларның экстерн сыйфатында арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу турындагы гаризасы нигезендә, өч эш көне эчендә чыгарыла торган боерык белән, җайга салына.

2.7. Боерыкта белем алу программасы буенча укучы арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен уза торган уку курслары, предметлар, дисциплиналар (модульләр) исемлеге, шулай ук аларны узу вакыты күрсәтелә,. Боерыкның күчермәсе балигъ булмаган баланың ата-аналарына (законлы вәкилләренә) яисә төп гомуми белеме булган яки унсигез яшькә җиткән укучыга бирелә.

2.8. Арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу вакытына белем бирү оешмасы:

2.8.1. китапханәдә булган дәреслекләр һәм башка әдәбият бирә;

2.8.2. укучыларга, аның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) гомуми белем бирү программасын үзләштерү өчен кирәкле методик һәм консультатив ярдәм күрсәтә;

2.8.3. укучыларга практик һәм лаборатор эшләр башкару өчен шартлар тудыра;

2.8.4. укучыга арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен экстерн узу хокукын бирә;

2.8.5. укучыларның академик бурычларын бетерү өчен шартлар тудыра һәм аны вакытында бетерүне контрольдә тота;

2.8.6. укучыларга белем бирү оешмасында укуларын дәвам итү мөмкинлеге бирә.

2.9. Экстернның арадаш аттестациясен үткәрү формалары, сроклары һәм тәртибе мәгариф оешмасы тарафыннан билгеләнә.

2.10. Балигъ булмаган бала ата-аналар (законлы вәкилләр) карары буенча, төп гомуми белем алганнан соң яисә гаиләдә белем алу яки үзлегеннән белем алган унсигез яшь тулганнан соң, белем алуның теләсә кайсы баскычында һәм теләсә кайсы этабында ул арадаш аттестация узган мәгариф оешмасында белем алуны дәвам итәргә хокуклы.

2.11. Балигъ булмаган баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) төп белем бирү программасы буенча укучыларга федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә, белем бирүнең тиешле дәрәҗәдә һәм тиешле этабында гомуми белем алуны тәэмин итәргә бурычлы.

2.12. Бер яки берничә уку фәне, курс, белем бирү программасы дисциплиналары (модульләре) буенча арадаш аттестациянең канәгатьләнмәслек нәтиҗәләре яки белем бирү учреждениесенең боеру акты белән билгеләнгән вакытта арадаш аттестация узмау, җитди сәбәпләр булмаганда, академик бурыч дип таныла. Укучылар академик бурычны белем бирү оешмасы билгеләгән срокларда бетерергә тиешләр.

2.13. Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча гаиләдә белеме һәм үзлегеннән белем алу рәвешләрендә белем алучылар, билгеләнгән вакытка академик бурычларын бетермәүчеләр, белем алуларын мәгариф оешмасында дәвам итәләр.

2.14. Белем бирү программаларын үзләштергәннән соң арадаш аттестацияне уңышлы узган очракта, гаиләдә белем алу яки үзлегеннән белем алу рәвешендә экстернага тиешле белешмә бирелә.

2.15. Уку елының төп гомуми белем программасын барлык уку курслары, предметлары, дисциплиналары (модульләре) буенча уңышлы үзләштергән экстерн арадаш аттестация нәтиҗәләре нигезендә, гаиләдә белем алу яисә үзлегеннән белем алу рәвешендә, бу хакта Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә әлеге нигезләмәнең 2.3 пунктында билгеләнгән тәртиптә, арадаш аттестация нәтиҗәләре алганнан соң, җиде эш көне эчендә, хәбәр итеп ,гомуми белем алуны дәвам итәргә хокуклы,

2.16. Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын укучыларга үзләштерү мәҗбүри дәүләт йомгаклау аттестациясе белән тәмамлана.

2.17. 9 һәм 11 (12) сыйныф укучыларына дәүләт йомгаклау аттестациясе мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы тарафыннан билгеләнгән формаларда һәм тәртиптә үткәрелә.

2.18. Укучыларга гаиләдә белем алу формасында белем бирү программаларын үзләштергәннән соң, дәүләт йомгаклау аттестациясе уңышлы булган очракта, төп гомуми белем турында дәүләт үрнәгендәге документ, үзлегеннән белем алу рәвешендә - урта гомуми белем турында дәүләт үрнәге булган документ бирелә.

## III. Гаиләдә белеме алу (үзлегектән белем алу ) формасында гомуми белем алучы гражданнарны исәпкә алу буенча эш башкару

3.1. Мәгариф идарәсе тарафыннан гаиләдә белем алу(үзлектән белем алу ) формасында гомуми белем алучы балаларны исәпкә алу журналында кергән гаризаларны теркәү һәм исәпкә алу алып барыла.

3.2. Экстерн арадаш һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узган белем бирү оешмасы Мәгариф идарәсенә экстернның арадаш аттестациясен узу һәм (яисә) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу турындагы документларны тапшыра.

2 нче кушымта
ТР ЗМР Башкарма комитеты
Карарына
26.12.2020 ел №2580

(Форма)

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
урынбасары - Мәгариф идарәсе
башлыгы Р. В. Афанасьевага

______________________________________

______________________________________

(баланың ата-аналарының (законлы
вәкилләренең) Ф. И. О.)
түбәндәге адрес буенча теркәлгән:

______________________________________

______________________________________

түбәндәге адрес буенча яшәүче:

______________________________________

______________________________________

______________________________________

тел. (өй)______________________________
(моб.)_________________________________

Гаиләдә белем алу формасында белем алу формасын сайлау турында

**ХӘБӘРНАМӘ**

Әлеге, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 63 статьясындагы 5 өлеше таләпләренә туры китереп, күрсәтелгән Федераль законның 17 статьясындагы 1 һәм 3 өлешләре, 44 статьясындагы 1 һәм 3 пунктлары, 63 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, без, балигъ булмаган баланың ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан түбәндәгеләрне хәбәр итәбез:
______________________________________________________________________
( баланың Ф. И.О)
_____________________________________________ туган елы,_______________________
_________________________________________________________________ сәбәп аркасында
(сәбәбен күрсәтергә)
аның өчен башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем алу (кирәклесенең астына сызарга ) гаиләдә белем алу формасы сайлап алына. Белем алу формасын һәм укыту формасын сайлау турында карар баланың фикерен исәпкә алып кабул ителде.

Дата______________________

_________________(________________________________)
Имза (имзаның аңлатмасы)

Хәбәрнамәгә кушымта итеп түбәндәгеләрне бирәм:

3 нче кушымта
ТР ЗМР Башкарма комитеты
карарына
26.12.2020 ел №2580

(Форма)

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
урынбасары - Мәгариф идарәсе
башлыгы Р. В. Афанасьевага
______________________________________
______________________________________
(баланың ата-аналары (законлы
вәкилләре) Ф. И. О.)
түбәндәге адрес буенча теркәлгән:
______________________________________
______________________________________
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
______________________________________
______________________________________
______________________________________
тел. (өй)____________________________

(моб.)_______________________________

ҮЗЛЕКТӘН БЕЛЕМ АЛУ ФОРМАСЫНДА ГОМУМИ БЕЛЕМ АЛУ ТУРЫНДА ХӘБӘРНАМӘ

Мин,_____________________________________________________________,
__________туган елым, гомуми белемне үзлектән белем алу формасында алачагым турында хәбәр итәм. Арадаш һәм (яки) дәүләт йомгаклау аттестациясен узу өчен экстерн сыйфатында түбәндәге гомуми белем бирү оешмасы билгеләнде:__________________________________________

Дата _____________

Имза______________(_____________________) (имзаның аңлатмасы)

4 нче кушымта
ТР ЗМР Башкарма комитеты
карарына
26.12.2020 ел №2580

(Форма)

______________________________________________________________
(экстернның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)

______________________________________________________________
( гомуми белем бирү учреждениесенең исеме, адресы)

______________________________________________________________
___________________ уку елында ______классның курсы өчен арадаш аттестация узды

| N т/б | Уку предметларының исеме | Чирек, яртыеллык, сыйныф, фәннең тулы курсы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |
| 5 | | | |
| 6 | | | |
| 7 | | | |
| 8 | | | |
| 9 | | | |
| 10 | | | |

Гомуми белем бирү учреждениесе директоры____________________(Ф. И. О.)

М.У.

"__" ___________ ______ел

___________________

5 нче кушымта
ТР ЗМР Башкарма комитеты
карарына
26.12.2020 ел №2580

(Форма)

## Гаиләдә белем алу яисә үзлектән белем алу формасында белем алучы балаларны исәпкә алу журналы

| №№ | Укучының Ф. И.О. | Туган көне | Белем алган белем бирү учреждениесенең исеме | Класс | Яшәү адресы | Ата-аналар турында мәгълүмат | Искәрмә (контактлар һ. б.) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|